ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2025 п.г.т.Алексеевское № 24

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 07.10.2024 елгы 268 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 9165,37 сум дип 2025 елның 1 февраленнән билгеләргә һәм гамәлгә кертергә (1 нче кушымта, 2 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_28.01.2025_ № _24__
карарына 1 нче кушымта

**2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында вафат булганнарны (һәлак булганнарны), ире(хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булган кешенең законлы вәкилләре булганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге**

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе (сумнарда.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 6068,82 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 732,89 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 2363,66 |
| Барлыгы | 9165,37 |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_28.01.2025_ № _24__
карарына 2 нче кушымта

**2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында вафат булганнарны (һәлак булганнарны), ире(хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булган кешенең законлы вәкилләре булмаганнарны җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге**

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе (сумнарда.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Мәетне киендерү | 329,79 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5739,03 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка алып бару | 732,89 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 2363,66 |
| Барлыгы | 9165,37 |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**